ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

28.09.2021 ел Баулы шәһәре №173

2022 елга Баулы муниципаль районында балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясенең нормативларын раслау турында

«Балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру нормативларын исәпләү буенча методик тәкъдимнәрне раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 5 июлендәге 545 номерлы карарының 2 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Кушымта итеп бирелә торган түбәндәгеләрне 2022 елга расларга:

2022 елга балалар йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең (1 нче кушымта) бәясе нормативлары;

балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең бәясен исәпләү тәртибе турында нигезләмә (2 нче кушымта).

2. Баулы муниципаль районының финанс-бюджет палатасына гомуми белем бирү оешмаларын әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең бәясн нормативлары нигезендә финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров

1 нче кушымта

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының
2021 елның 28 октябрендәге
173 номерлы карары белән
расланган

2022 елга балалар йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең (1 нче кушымта) бәясе нормативлары

| Автотранспорт чарасы моделе атамасы | Ике ставкалы норматив күләме | |
|---|---|---|
| | бер автотранспорт чарасына ставка, елына сумнарда | автотранспорт чарасының бер километрына ставка, сум |
| КАВЗ | 154152 | 38,77 |
| ПАЗ | 153591 | 38,68 |
| ГАЗ «Газель» | 133242 | 31,16 |
| УАЗ | 132789 | 29,69 |
| FIAT | 136630 | 28,02 |
| Peugeot Boxer | 142063 | 27,66 |
| Ford Transit | 142320 | 31,34 |
| Камаз Марко-Поло3297 | 156063 | 36,63 |

1 нче кушымта

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының
2021 елның 28 октябрендәге
173 номерлы карары белән
расланган

балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең бәясен исәпләү тәртибе турында нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмалары укучыларын ташуны оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең хакын исәпләү механизмын (алга таба - муниципаль хезмәт) билгели.

1.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе муниципаль хезмәт күрсәтү бәясенең, автотранспорт чаралары санының һәм хисап чорына автотранспорт чараларының фактта йөрүенең нормативы нигезендә исәпләнә.

1.3. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең хакы нормативлары ел саен Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана.

1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен формалаштырганда Татарстан Республикасында автотранспорт чараларының аерым төрләрен мониторинглауның бердәм системасы мәгълүматлары нигезендәге автотранспорт чараларының хисап елында фактта күпме километр узганы турында мәгълүмат автотранспорт чарасының расланган паспорты кысаларында башкарылган автотранспорт чарасының фактик йөгереше буларак кабул ителә.

2. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү

2.1. i-муниципаль берәмлекнең муниципаль хезмәтен күрсәтү бәясе түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$S_i = \sum_{m=1}^{k} (n_{f\,m} \times NF_{km_m} + NF_{as\,m} \times M_m),$$

$S_i$ - муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе;

$n_{f\,m}$ - m модельле автотранспорт чараларының фактик йөгереше, километр;

$NF_{km_m}$ - балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән гомуми белем бирү оешмалары укучыларын ташуны оештыру бәясенең бер километрга нормасы, сум;

$NF_{as\,m}$ - балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән гомуми белем бирү оешмалары укучыларын ташуны оештыру бәясенең бер автотранспорт чарасына нормасы ставкасы, сум;

$M_m$ - m модельле автотранспорт чаралары саны, берәмлек;

$m$ - муниципаль берәмлектә кулланыла торган автобус моделе исеме;

$k$ - муниципаль берәмлектә кулланыла торган автобуслар саны.